**СОВЕТ ТАШЛЫ-КОВАЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422716, Республика Татарстан, Высокогорский район, с.Ташлы-Ковали, ул. Школьная, 94

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТАШЛЫ КАВАЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422716, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Ташлы Кавал ав, Мэктэп. ур., 94

тел./факс 8(84365) 70-4-16, e-mail: Tkv.Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
**31 август 2026 ел** **№ 23**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Ташлы Кавал авыл җирлеге Советының "Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Ташлы Кавал авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәне раслау турында" 18.11.2019 елның 161 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Муниципаль норматив-хокукый актларны хокукый мониторинг нәтиҗәләре буенча гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында Биектау районы Прокуратурасы 2026 елның 20 июлендәге 02-08-01 номерлы, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Ташлы Кавал авыл җирлеге советы протестын үтәүдә **КАРАР:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Ташлы Кавал авыл җирлеге советы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Ташлы Кавал авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә (12.02.2020 № 174, 19.11.2020 № 11, 03.09.2021 № 29, 28.02.2023, № 58, 14.09.2023 № 65, 28.06.2024 номерлы, 22.11.2024 номерлы, 2024 елның 13.02.109 номерлы карарлар редакциясендә) муниципаль хезмәт турында Положениегә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә::

1.1 13 статьяның 1, 2 пунктларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучы граждан, муниципаль хезмәткәр яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) “Коррупциягә каршы көрәш турында” 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда, әлеге Федераль законда билгеләнгән очракларда, керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыра. Күрсәтелгән белешмәләр «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан каралган керемнәр, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру өчен билгеләнгән тәртиптә, срокларда һәм формада тапшырыла.

2. Тиешле исемлеккә кертелгән муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче муниципаль хезмәткәр «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм аларның керемнәренә башка затлар чыгымнарының туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законда каралган чыгымнар турында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан мондый белешмәләрне тапшыру өчен билгеләнгән тәртиптә һәм рәвештә белешмәләр тапшырырга тиеш.»

1.2. 13 статьяның 4 пунктында «керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында» сүзләрен төшереп калдырырга.

1.3. 13 статьяның 5 пунктында «керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр» сүзләрен «муниципаль хезмәткәргә әлеге статья нигезендә тапшырыла торган белешмәләр,» сүзләренә алмаштырырга

1.4. 13 статьяның 6 пунктында «муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр» сүзләрен «муниципаль хезмәткәргә әлеге статья нигезендә тапшырыла торган белешмәләр,» сүзләренә алмаштырырга.

1.5. 13 статьяның 7 пунктында «үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр» сүзләрен «дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда каралган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр» сүзләренә алмаштырырга;

1.6. 13 статьяның 10 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Контракт буенча башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар әлеге статьяның 1 пунктында күрсәтелгән белешмәләрне, мондый вазыйфаны биләүче зат әлеге статьяның 1 һәм 2 пунктларында күрсәтелгән белешмәләрне Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы башлыгына (Раивына) тапшыра».

1.7. 13 статьяның 11 пунктын үз көчен югалткан дип таныргa.

1.8. 14 статьяның 3 пунктындагы 10 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10) «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда каралган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр;».

2. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырып игълан итәргә: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ һәм

Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru

Ташлы Кавал авыл җирлеге башлыгы,
Башкарма комитет җитәкчесе И.И.Хайбуллин